## Иманга юл

# ИБРАҺИМ ӘДҺӘМ хикәяте



Алланың изге бәндәләреннән Әдһәм атлы изге бер бәндәсе бар иде. Көннәренең күбесен зиратта, каберләр арасында үткәрә иде.

Ул яшәгән Бәлех шәһәрендә падишаһның бик чибәр бер кызы бар иде. Падишаһ сараеның биектәге тәрәзәсеннән башын чыгарып, астагы кешеләрне күзәтер иде. Бу кызга Әдһәмнең күзе төште, чибәрлегенә исе китеп, ул падишаһның кызына мең җан белән гашыйк булды. Аннан соң ул аны күрергә һәм үзенә кияүгә алырга теләп, шәһәр эченә керде, падишаһтан кызны сорарга ниятләде. Падишаһка сүз кушарга кыюлыгы җитмичә, нәүмиз булып тилмереп карап торды. Падишаһның аңа күзе төшү белән аңлады: бу фәкыйрьнең аңа бер-бер йомышы бар булса кирәк.

Падишаһ яраннары белән мәчеттән кайтып килә иде. Бу Әдһәмнең падишаһка эндәшергә көче җитмәде, өметсезләнеп, тилмереп карап калды.

Падишаһ:

- Бу фәкыйрьнең берәр йомышы бар, ахры, - диде.

Вәзир ул фәкыйрь янына барды, хәлен сорады:

- Нинди үтенечең бар? - диеп.

Әдһәм әйтте:

- Падишаһның кызын никях итеп бирүен сорыйм, - диде.

Вәзир падишаһ янына килде. Падишаһ сорады:

- Ул фәкыйрьнең ни үтенече бар? - диде.

Вәзир кыяр-кыймас әйтте:

- Синең кызыңны хатынлыкка сорыйдыр.

Моны ишетеп, падишаһның барча вәзирләре хәйранга калдылар. Аннан соң падишаһ вәзирләре белән: “Ни дип әйтик?” - дип киңәште. Ахырда шулай киңәш итештеләр:

- Мәһәре күп, дип әйт, көче җитмәс, теләгеннән кире кайтыр, - диделәр.

Шаһ әйтте:

- Моның хәле өч хәлнең берседер - йә бу бер олы кешедер, йә бер диванадыр, йә кешеләрне сынаучыдыр.

Шаһның ике эре энҗесе бар иде, ул заманда һичкемдә моңа тиң энҗеләр юк иде. Һәр икесен китерделәр. Әдһәмгә әйттеләр:

- Әгәр боларга охшашлыны табып китерсәң, кыз синекедер.

Әдһәм моны ишеткәч, яхшы булыр, дип кире кайтып китте. Бер күл читенә барды, кулына бер чиләк алып, күлнең суын түгә башлады. Ярдәмчеләренә дә кушты, алар да түктеләр. Шулай итеп, ул күлнең суын бераз киметтеләр.

Кул эчендәге җан ияләре Аллаһы Тәгаләгә ялвардылар. Аллаһы Тәгалә ул җанварларга шәфкать итеп күңелләренә илһам салды:

- Барыгыз, Әдһәмнең максатын хасыйл итегез, юкса сезне корыда калдырып һәлак итәр.

Аннан соң ул күлнең җанварлары үз араларыннан бер өлкәнен Әдһәмгә илче итеп җибәрделәр. Әдһәмнең үтенечен белделәр, аның теләген канәгатьләндерү өчен һәрберсе авызына кабып берәр зур энҗе алып килде. Әдһәм ул җанварлардан утыз җеп энҗе җыеп алды. Аннары барысын да кире кайтарды:

- Барыгыз, мин сездән канәгатьмен, - диде.

Аннан соң Әдһәм ул энҗеләрне алып, падишаһ каршына барды, ике энҗене күрсәтте, ә калганнарын яшерде. Әдһәмнең бу энҗеләре шаһның энҗеләренә караганда мең тапкыр артык булды. Падишаһ һәм яраннары хәйран калдылар, ни әйтергә дә белмәделәр.

Ахырда:

- Син караксың, шаһның энҗеләрен каян урладың! - дип яла ягып, йөзенә караганнар иде. Әдһәм, шундук куеныннан яшергән энҗеләреннән тагын икесен чыгарып:

- Болары да сезнекеме? - диде. Тагын икене чыгарды, тагын, тагын чыгарды... Падишаһ тәмам яраннары белән хәйранга калдылар, ни сүз әйтергә белмәделәр, тыннары кысылды.

Әдһәм:

- Әгәр мине кабул итеп, кызыгызны бирмәсәгез, үзегезгә булсын кызыгыз! - дип, ул куеныннан чыгарган энҗеләрне аларына сибеп җибәрде, кулына икесен генә алып калды. Үзе кире үзенең торган почмагына кайтып китте.

Әдһәм киткәч тә, шаһның кызына гаять тә авыр чир эләкте. Шундук шул заманның күренекле табибларын, имчеләрен чакырдылар, ләкин һичбер чарасын таба алмадылар. Кыз үлде. Һәммәсе дә чиксез кайгылы булып, гамь вә хәсрәт эчендә зиратка киттеләр, кызны табуты белән төрбәгә куйдылар.

Әдһәм дә бу хәлне белде, падишаһ кызының төрбәсенә барып, уйлап-исәпләп утырды:

- Мин бу падишаһ кызын исән вакытында күзем туйганчы күрә алмадым, һич булмаса, үлгән булса да, бер күзем туйганчы күрим, - дип, куеныннан баягы энҗеләрне чыгарды, кабер эче шундук яп-якты булды.

Шул хәлдә Әдһәм бу падишаһ кызын карап тора иде. Бу вакыт шул шәһәрнең бик оста бер им-томчы карчыгы кич белән табиблыктан кайтып килә иде: кабер өстендә әлеге нурны күрде.

- Бу нинди нур икән? - дип, яннарына барды, хәлләрен күрде, гажәп вә хәйранга калды: - Бу ни хәл? - диде.

Әдһәм ул карчыкка башыннан үткәннәрне бәян итте. Ул карчыкның Әдһәмнең хәленә шәфкате килде, ярдәм итәргә теләде. Ул кызның йөзенә карады: йөзен нурлы күрде. Аннан соң әйтте:

- Мин моның хәлен карап карыйм, ничек икән, - диде. Кулын тотып карады, әйтте: - Бу кызга әҗәл җитмәгән икән, каны гына бозылган икән, кан тамырына чиртсәң, шундук сихәт табар, - диде.

Әдһәм ул карчыкка үтенде. Карчык аны тыңлады, пәкесен чыгарып, кызның кан тамырына чиртте, ягъни аз гына кисеп, канын чыгарды. Падишаһ кызы шундук сихәт тапты, күзен ачып карады, үзен кабер эчендә күрде.

- Бу ни хәл, - диде. Вә янә Әдһәмгә әйтте: - Син кемсең?

Әдһәм аңа башыннан кичкәннәрне бер-бер артлы сөйләп бирде. Кыз Әдһәмнән бу хәлләрне ишеткәч:

- Инде мин сиңа кол булам, - диде.

Аннан соң Әдһәм ике энҗене ул карчыкка биреп бәхилләтте.Ул падишаһ кызын өенә алып кайтып, үзенә никях итте. Әдһәм белән кызның мәхәббәтләре көннән-көн арта барды. Аллаһы Тәгалә Әдһәмгә ул падишаһ кызыннан бер ир бала бүләк итте. Исемен Ибраһим дип куштылар. Малай гаять тә чибәр иде.

Көннәрдән бер көнне шаһ үзенең яраннары белән аудан кайтып килгәндә бу Әдһәмнәрнең урамыннан үтте, Ибраһим урамда юл өстендә уйнап йөри иде. Шаһның бу балага күзе төште, хәйранга калды:

- Бу бала минем кызыма охшаган икән, - дип, кулына алып, үбә-коча сөйде, һәм янә малайның кем баласы икәнен сорап белү өчен җанын фида кылыр чиккә җитте.

Бу вакыт Әдһәм улын эзләпсораштырып, улы Ибраһимны шаһ янында тапты. Шаһ аны күрү белән:

- Бу бала минем кызыма бик тә охшаган, моның әнисе кем? - дип сорады.

Әдһәм:

- Үз кызың булмый, кем булсын, - дип, башыннан узган хәлләрне баштанаяк сөйләп бирде. Шаһ бик гаҗәпләнде, чиксез сөенде.

Ибраһимны әнисе һәм әтисе белән бергә яхшы әсбаплар җибәреп, сарайга алдырдылар. Үз улларыннан да артыграк итеп тәрбия иттеләр. Әдһәм монда озак калмады, углын әнисе белән бергә сарайга тапшырганның соңында ялгызлыкта аерым яшәүне ихтыяр итте, Мәккәгә Изге йортка сакчылыкка китте.

Ул шаһның Ибраһимнан гайре улы юк иде. Ибраһим үсеп, балигъ булгач, бабасы шаһ вафат булды. Бабасы урынына Ибраһимны Бәлех шәһәренә падишаһ итеп куйдылар. Ибраһим күп гомерен Аллага гыйбадәт белән үткәрде.

Беркөн Ибраһим үз сараенда Аллага якынаю теләге белән Алланы данлау һәм мактау сүзләрен укып утыра иде. Сарай өстендә нидер эзләп йөрүче берәүне күрде. Ул кешене чакыртып китерде:

- Сарай өстендә әдәпсезләнеп нишләп йөрисең? - диде.

Сарай өстенә менгән кеше әйтте:

- Мин моннан алма эзлим, - диде.

Ибраһим:

- Ахмакмы әллә син, сарай өстендә нинди алма булсын? - диде.

Ул кеше җавап кайтарды:

- Синме ахмак, юкса минме ахмак, тәхет өстендә утырып, Аллаһы Тәгаләгә якынлык телисең.

Ибраһим фикер итте: “Бу миңа бер кисәтү”, - дип, көннәрдән бер көнне тәхет һәм малын ташлап, читкә, аулак җиргә китәргә ниятләде. Әмма күңеленә килде: “Мин киткәннән соң минем кебек гадел хөкем белән кем тотар бу халыкны һәм бу җәмәгатьләремне кем туйдырыр?”.

Шул фикер белән хөкем сараенда утыра иде. Кинәт күрекле, затлы бер кеше аның каршына килде. Ул Ибраһимнан кунак булырга Кәрвансарай сорады.

Ибраһим әйтте:

- Бу нинди кәрвансарай булсын, бу хөкем йорты, - диде.

Ул кеше әйтте:

- Синнән әүвәл монда кемнәр шаһ булып урын тоттылар?

Ибраһим:

- Миннән әүвәл бабам иде, аннан әүвәл фәлән, - дип кызып китте.

Ул кеше Ибраһимга җавабында әйтте:

- Шулай булгач, ничек кәрвансарай булмасын: алар монда кунак булганнар да киткәннәр, хәзер исә син кунак, син киткәч, башкалар килер, гаделлек белән хөкем итәрләр, - диде.

Моның бу сүзе белән Ибраһим тагын бер кат искәртелде.

Көннәрдән бер көнне Ибраһим үзенең вәзирләре белән сәйранга, ауга чыктылар. Күп юл үттеләр. Йөри торгач, кояшны томан басып китте. Юлларын адашып, кая барырга белмәделәр. Таралышып, төрле тарафтан юл эзләделәр. Ибраһим ике вәзире белән бер якка китте. Бик каты тамаклары ачты. Бераздан томан күтәрелде. Ике вәзирнең берсенең куенында бер күмәч бар иде. Шуны ашыйбыз дип, бер таш өстенә куйдылар. Кинәт кенә һавадан бер карга төшеп, күмәчне алып китте. Хәйран булып, кычкырышып, ул карганы куа киттеләр. Аны куалаганда Ибраһим вәзирләреннән аерылды. Карга бер тау өстенә кунды. Ибраһим атын шунда куалады. Ул тауның түбәсендә кул-аягы богауланган бер карт кешене күрде. Ибраһим күрде: карга, күмәчне бу картның күкрәгенә куеп, картны ашата. Ибраһим ул картның янына барды, хәлен сорады.

Карт әйтте:

- Мин күп малның хуҗасы идем. Юлбасарлар минем юлымны кистеләр, малымны алдылар, үземнең кул-аягымны бәйләп, шушылай итеп киттеләр. Аллаһы Тәгаләнең әмере белән шул көннән бирле бу карга миңа шулай килеп йөрде, ризык китереп ашатты, - диде.

Ибраһим аның кул-аягын чиште, үзе бер якка китте һәм әйтте:

- Аллаһы Тәгалә ризык биреп торучы падишаһтыр, минем җәмәгатьләремне дә ризыксыз иткәрмәс, - дип юк-бар уйларын ташлап, бер көтүче янына килде. Өстендәге падишаһлык киемнәрен көтүчегә биреп, үзе көтүченең киемнәрен киде. Кешеләрдән аерылып, ялгызлыкта Ходайга дога кылып яшәүне ихтыяр итте. Шулай итеп, әтисе Әдһәм юлыннан китте.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рабиғүл әүүл-Рабиғүл ахыр 2012 миләди йыл 1433 һижри йыл.**

| Сәфәр-Рабиғүл-әүүәл | Аҙна көндәре | Январь, Февраль | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Шаршамбы | 16 | 9.02 | 10.32 | 14.30 | 16.50 | 18.20 | 19.50 |
| 5 | Кесе йома | 17 | 9.00 | 10.30 | 14.30 | 16.52 | 18.22 | 19.52 |
| 6 | Йома | 18 | 8.59 | 10.29 | 14.30 | 16.54 | 18.24 | 19.54 |
| 7 | Шәмбе | 19 | 8.58 | 10.28 | 14.30 | 16.56 | 18.26 | 19.56 |
| 8 | Йәкшәмбе | 20 | 8.57 | 10.27 | 14.30 | 16.58 | 18.28 | 19.58 |
| 9 | Дүшәмбе | 21 | 8.55 | 10.25 | 14.30 | 16.59 | 18.29 | 19.59 |
| 10 | Шишәмбе | 22 | 8.54 | 10.24 | 14.30 | 17.01 | 18.31 | 20.01 |
| 11 | Шаршамбы | 23 | 8.53 | 10.23 | 14.30 | 17.03 | 18.33 | 20.03 |
| 12 | Кесе йома | 24 | 8.51 | 10.21 | 14.30 | 17.05 | 18.35 | 20.05 |
| 13 | Йома | 25 | 8.50 | 10.20 | 14.30 | 17.07 | 18.37 | 20.07 |
| 14 | Шәмбе | 26 | 8.48 | 10.18 | 14.30 | 17.09 | 18.39 | 20.09 |
| 15 | Йәкшәмбе | 27 | 8.46 | 10.16 | 14.30 | 17.11 | 18.41 | 20.11 |
| 16 | Дүшәмбе | 28 | 8.45 | 10.15 | 14.30 | 17.13 | 18.43 | 20.13 |
| 17 | Шишәмбе | 29 | 8.43 | 10.13 | 14.30 | 17.15 | 18.45 | 20.15 |
| 18 | Шаршамбы | 30 | 8.41 | 10.11 | 14.30 | 17.17 | 18.47 | 20.17 |
| 19 | Кесе йома | 31 | 8.40 | 10.10 | 14.30 | 17.20 | 18.50 | 20.20 |
| 20 | Йома | 1 | 8.38 | 10.08 | 14.30 | 17.22 | 18.52 | 20.22 |
| 21 | Шәмбе | 2 | 8.36 | 10.06 | 14.30 | 17.24 | 18.54 | 20.24 |
| 22 | Йәкшәмбе | 3 | 8.34 | 10.04 | 14.30 | 17.26 | 18.56 | 20.26 |
| 23 | Дүшәмбе | 4 | 8.32 | 10.02 | 14.30 | 17.28 | 18.58 | 20.28 |
| 24 | Шишәмбе | 5 | 8.30 | 10.00 | 14.30 | 17.30 | 19.00 | 20.30 |
| 25 | Шаршамбы | 6 | 8.28 | 9.58 | 14.30 | 17.32 | 19.02 | 20.32 |
| 26 | Кесе йома | 7 | 8.27 | 9.57 | 14.30 | 17.34 | 19.04 | 20.34 |
| 27 | Йома | 8 | 8.25 | 9.55 | 14.30 | 17.36 | 19.06 | 20.36 |
| 28 | Шәмбе | 9 | 8.22 | 9.52 | 14.30 | 17.38 | 19.08 | 20.38 |
| 29 | Йәкшәмбе | 10 | 8.20 | 9.50 | 14.30 | 17.40 | 19.10 | 20.40 |
| 1 | Дүшәмбе | 11 | 8.18 | 9.48 | 14.30 | 17.43 | 19.13 | 20.43 |
| 2 | Шишәмбе | 12 | 8.16 | 9.46 | 14.30 | 17.45 | 19.15 | 20.45 |
| 3 | Шаршамбы | 13 | 8.14 | 9.44 | 14.30 | 17.47 | 19.17 | 20.47 |
| 4 | Кесе йома | 14 | 8.12 | 9.42 | 14.30 | 17.49 | 19.19 | 20.49 |
| 5 | Йома | 15 | 8.10 | 9.40 | 14.30 | 17.51 | 19.21 | 20.51 |